| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.03.2020 г.Лениногорск № 33

«Яңа Елхово нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» линияле объектына аның составында территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү

Халыкның муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын үтәү, кеше тормышының уңай шартларына, җир кишәрлекләренә ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе, 5.1 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы ¸ «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 23 гыйнварындагы 58 номерлы карары нигезендә әзерләнгән «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Яңа Елхово нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» линияле объектына составындагы территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрелә башлау турында хәбәр итәргә.

2. 2020 елның 27 мартыннан 29 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Яңа Елхово нефть ятмасының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» линия объектына территорияне